ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

| | | |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**10.10.2024** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 3861** |

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 27 февралендәге 354 номерлы карары белән расланган, «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында тәрбияләнүчеләрне караган һәм тәрбияләгән өчен ата-ана түләвен формалаштыру һәм алу тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» 2019 елның 02 июлендәге 546 номерлы карары нигезендә, «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең мәктәпкәчә мәгариф оешмалары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру һәм автономиясен тәэмин итү, мәктәпкәчә белемгә бюджет хезмәте күрсәтүнең сыйфатын арттыру максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 27 февралендәге 354 номерлы карары белән (16.04.2015 ел, № 845, 16.05.2022 ел, № 1149 карарларына кертелгән үзгәрешләре белән) расланган, «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында балаларны караган һәм тәрбияләгән өчен ата-ана түләвен формалаштыру һәм алу тәртибенә (алга таба-Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Тәртипне түбәндәге эчтәлекле 2.3.1. һәм 2.3.2 пунктлары белән тулыландырырга:

«2.3.1. Ата-ана түләвен түләүдән яисә аны 50 процент күләмендә түләүдән азат итү хокукын раслау өчен ата-ана (законлы вәкилләр) түбәндәге документларны тапшыра:

- ташламалар бирү турында муниципаль белем бирү оешмасы җитәкчесе исеменә язмача гариза;
- балалар туу турында таныклык;

күрсәтелгән документлардан тыш, гражданнарның аерым категорияләре өстәмә рәвештә түбәндәге документларны тапшыралар:

- өч һәм аннан да күбрәк бала тәрбияләүче ата – аналар (законлы вәкилләр) - күпбалалы гаилә таныклыгының күчермәсен яисә өлкән бала 18 яшькә яисә 23 яшькә җиткәнче, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмада белем алуның

көндезге формасында белем алса,шуны  раслый торган документ (уку урынынннан белешмә), күпбалалы гаилә статусын билгеләү турында карар;

- опекуннар, тәрбиягә бала алучы ата-аналар - ата-ананы алмаштыручы статусын раслый торган хокукый актның күчермәсе;

- инвалид баланың ата-анасы - медицина бәяләмәсеннән инвалидлык турында белешмә күчермәсе.

Ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) күрсәтелгән ташламаларны алу хокукы әлеге Тәртипнең шушы пункты нигезендә рәсмиләштерелгән гариза биргән айдан агымдагы айның 20 числосына кадәр кертеп бирелә. Документлар 20 айдан соң бирелгән очракта ташлама киләсе айдан бирелә.

Ата-аналар (законлы вәкилләр) тапшырыла торган документларның дөреслеге һәм чын булуы өчен җаваплы.

Ташлама бирү турындагы гариза һәм аңа кушып бирелә торган документлар мәгариф оешмасы җитәкчесе тарафыннан 3 эш көне эчендә карала, муниципаль оешма җитәкчесе тарафыннан карау нәтиҗәләре буенча ташлама бирү турында яисә бирүдән баш тарту турында карар кабул ителә.

2.3.2. Әлеге Тәртипнең 2.2.-2.3 пунктларында каралган ташламалар бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

- әлеге Тәртипнең 2.3.1 пунктында күрсәтелгән документларның тулы булмаган исемлеген бирү;

- тәкъдим ителгән документлардагы белешмәләрнең дөрес булмавы.

Ата-аналар (законлы вәкилләр) кабул ителгән карар турында, аны кабул иткән датадан алып 3 эш көне эчендә, хәбәр ителәләр.

Ташламага берничә нигез буенча хокуклы ата-аналарга (законлы вәкилләренә) ташлама нигезләрнең берсе буенча билгеләнә».

2. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсенә әлеге карарны ведомство карамагындагы учреждениеләр җитәкчеләренә җиткерергә.

3. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының (http://pravo.tatarstan.ru) рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) сайтында урнаштырыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карар белән кертелгән үзгәрешләр 2024 елның 01 августыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары - Мәгариф идарәсе башлыгы Р.В. Афанасьевага йөкләргә.

Җитәкче З.Ф. Хәбибуллин